**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш XV утырыш
**КАРАРЫ**

2023 елның 1 октябре №54 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 29.10.2021 № 83 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2014 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 12.10.2023 ел, № 01-54/7098 «Куркыныч индикаторлары турында»гы хаты белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2021 елның 29 октябрендәге 83 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә түбәндәге өстәмәләр кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 8 статья өстәргә:

**«8. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1) Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм торак пункт чикләрендә юл хуҗалыгында һәм (яисә) җирле әһәмияттәге бер үк юлда муниципаль контроль объектында утыз календарь көн дәвамында ике һәм аннан күбрәк юл-транспорт вакыйгасы;

2) Автомобиль транспортында, шәһәр, җир өсте, электр транспортында, йөртүчеләр тарафыннан кылынган, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрен кимендә биш процентка һәм аннан да күбрәк бозу фактларын, бер календарь ел дәвамында, алдагы календарь ел белән чагыштырганда, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә бирелгән белешмәләр нигезендә, даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутында юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу фактлары артуы;

3) ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан бирелгән белешмәләр нигезендә юл-транспорт вакыйгалары санын бер календарь ел дәвамында юл инфраструктурасы объектында ике мәртәбә һәм аннан да күбрәк тапкыр артуы;

4) Контрольдә тотыла торган зат карамагындагы яисә аннан файдаланудагы юл участогында юл-транспорт һәлакәтләренең узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, календарь айга биш процентка артуы;

5) Хисап елы дәвамында юлның бер участогында яки юллар һәм урамнар киселешендә кешеләр зыян күргән яки яраланган канәгатьләнерлек булмаган юл шартлары белән бәйле рәвештә бер төр юл-транспорт вакыйгасы барлыкка килүенең өч һәм аннан да күбрәк факты ачыклануы.

2. «Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2021 елның 29 октябрендәге 83 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында» 2022 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара эшчәнлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы башлыгы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин